**МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ**

**БОЕРЫК**

25.12.2015

Казан ш.

№ 3332-р

**Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында**

1. Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән Административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында карар проекты әзерләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында” 2013 елның 25 ноябрендәге 3598-р номерлы карары көчен югалткан дип танырга (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2013 елның 10 декабрендә теркәлгән, теркәлү номеры 2117);

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

**Министр в.б.** **С.А.Демидов**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының
25.12.2015, № 3332-р карары белән расланды

**Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән (федераль милектәге җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: юридик һәм физик затлар, шәхси эшмәкәрләр.

Дәүләт хезмәтен алуга гариза бирүчеләр булып дәүләт хезмәтен алучылар яисә дәүләт хезмәтен алучының тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче вәкаләтле вәкилләре (алга таба – гариза бирүче) санала.

1.3. Дәүләт хезмәтен түбәндәгеләр күрсәтә:

Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) - авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында үтенеч язуын карау буенча, авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты (алга таба – ТР МК) – авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын кабул итү.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Гариза бирүчеләрдән мөрәҗәгатьләр кабул итү: чәршәмбе 14.00дән 16.00 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43 номерлы автобуслар белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – “Сукно бистәсе”.

1.3.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге (алга таба - Бүлек): 221-40-36, 221-40-37, 1-49 (эчке), 1-50 (эчке).

1.3.3. Министрлыкның “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – Интернет челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

Электрон почта адресы: mzio@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган дәүләт хезмәте турында Министрлык эчендә урнаштырылган мәгълүмат стендларыннан;

2) “Интернет” челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

Мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 1.3.2, 2.1, 2.3, 2.4, 2,5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм, гариза бирүчеләр белән эшләү өчен, Министрлык бинасындагы мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ЖК) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4147 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерация Шәһәр төзү кодексы (РФ законнары җыелмасы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеш), ст. 16, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында” 21.07.1997, № 122-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 122-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, ст. 3594) кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында” 25.10.2001, № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4148 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерү турында» 2004 елның 21 декабреннән 172-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон № 172-ФЗ) (РФ законнары җыелмасы, 27.12.2004, № 52 (1 өлеш), ст. 5276, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерация Шәһәр төзү кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2006 елның 18 декабреннән 232-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыелмасы, 25.12.2006, № 52 (1 ө.), ст. 5498, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында” 24.07.2007, № 221-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 221-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 30.07.2007, № 31, 4017 ст.);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010 ел, № 31, 4179 ст.);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, ст. 2338);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (1 кисәк), 4 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 ел, № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 21.12.2005, № 47-48, 0985 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл хуҗалыгы әһәмия-тендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турындагы үтенечнамә формасын һәм аңа теркәлә торган документлар составын раслау хакында» 2006 ел, 25 октябрь, 523 нче карары (алга таба – ТР МК карары № 523) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 08.11.2006, № 41-42, 1061 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре" 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 03.10.2007, № 37, 1379 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында" 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында" 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 19.10.2011, № 39, 1928 ст. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

"Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе турында" 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары

һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 2012, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) дөреслеккә туры килмәвенә китерүче министрлык хатасы (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында үтенечнамә (алга таба – үтенечнамә) – № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясының 1 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос. Үтенечнамә формасы ТР МКның №523 карары белән расланган.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү | РФ ҖК; ТР ҖК;<br>Федераль закон № 172-ФЗ;<br>Федераль закон № 221-ФЗ;<br>ТР МК карары КМ РТ № 523;<br>Нигезләмә |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Министрлык - үтенечнамәне карау буенча, авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү;<br>ТР МК – авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында карар кабул итү. | Нигезләмәнең п. 3.3.26 |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге | РФ ҖК; ТР ҖК;<br>Федераль закон № 172-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында ТРМК карары<br>Үтенечнамәне һәм аңа теркәлгән документларны караудан баш тарту турында хат | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып | Дәүләт хезмәте үтенечнамә кергән көннән, түбәндәгеләрне дә кертеп, ике ай вакыт эчендә күрсәтелә:<br>үтенечнамәне карау һәм авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү, яки үтенечнамәне һәм аңа теркәлгән документларны караудан баш тарту турында хат өчен 30 көн вакыт;<br>авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында ТР | Федераль закон № 172-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | МК карары кабул итү срогы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентына туры китерелә | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү өчен гариза бирүче Министрлыкка үтенечнамә яза. Үтенечнамә формасы ТР МК № 523 карары белән расланган.<br><br>Үтенечнамәгә теркәлә (һәрберсе берәр данә):<br>1) дәүләт экологик экспертиза бәяләмәсе (аны үткәре федераль законнарда карлган очракта);<br>2) җир кишәрлеген бер категория составыннан башкасына күчерергә җир кишәрелегенә хокук иясенең ризалыгы; җир кишәрелегенә хокук иясенең җир кишәрлегенә сервитут урнаштыру турында килешү төзелгән зат булуы искәрмә булып тора.<br>Дәүләт һәм муниципаль милек булган җир кишәрлеген күчерүгә ризалыгын әлеге җир кишәрелеге белән эш итәргә вәкаләтләре булган җирле үзидарә органы карар | Федераль закон № 172-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | формасында бирә;<br>3) Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр 1:25000 яисә 1:10000 масштабында алынган, соралган җир кишәрлегенең чикләре билгеләнгән, торак пунктларының чикләре һәм исемнәре, файдалана торган җирләрнең төрләре, гидрография элементларының чикләре һәм автомобиль юллары күрсәтелгән<br>план-картография материалы;<br>4) ышанычнамә (гариза бирүченең вәкиле үтенечнамәне имзалаган очракта);<br>5) җирле үзидарәнең вәкаләтле органының җир кишәрлеген бирүне алдан килештерү карары (җир кишәрлеге дәүләти яисә муниципаль милек булган җирләрдән РФ ҖКның 39.15 статьясының 1 пункты 6 подпунктында күрсәтелгән нигездә бирелгән очракта, җир кишәрлеген ясау яисә чикләрен аныклау зарурлыгы булганда), җир кишәрлеген ясарга кирәк булса һәм чикләрендә җир кишәрлеген ясарга кирәк булачак территориянең ызанлау проекты булмаган очракта, җир кишәрлегенең кәгазьгә сызылган урнашу схемасын теркәлә; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 6) җир кишәрлеген арендага алу шартнамәсе күчермәсе (ул төзелгән һәм Күчемсез милеккә һәм алар белән бәйле алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында аренда хокукына чикләүләр (комачаулыклар) булмаган очракта);<br>7) 2018 елның 1 мартына кадәр - җирле үзидарә вәкаләтле органының объектны урнаштыру урынын алдан килештерүнең 2015 елның 1 мартына кадәр, әмма РФ ҖКының 31 һәм 32 статьяларына туры китереп җир кишәрлеге бирелгәннән өч елдан да артыграк булмаган вакытта кабул ителгән карары («Россия Федерациясе җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 20 июнендә кабул ителгән 171-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән редакциядә), объектның урнашу урыны алдан килештерелгән җир кишәрлеген сайлау акты да теркәлә (җир кишәрлеге дәүләти яисә муниципаль милек булган җирләрдән бирелсә). | |

| | | |
|---|---|---|
| | 8) җир кишәрлеге файдалы казылмалар чыгару белән бәйле рәвештә күчерелсә – үтенечнамәгә теркәлә:<br>Нотариаль расланган яисә җитәкченең яки ул вәкаләтләр тапшырган вазыйфаи затның имзасы куелган һәм җир асты байлыкларын файдаланучы оешманың мөһере сугылган (мөһере булса) түбәндәге күчермәләр:<br>җир асты байлыкларын хокук лицензиясе;<br>лицензиягә (булган очракта) өстәмә килештерүләр (өстәмәләр);<br>план-картография материалында тау отводы чикләре билгеләнгән тау отводы картасы (таяну, параметрик, структур, эзләү, бәйләү һәм разведка скважиналарын урнаштыру искәрмә булып тора);<br>9) файдалы казылмалар чыгару белән бәйле очракларда тиешле тәртиптә расланган җирне рекультивацияләү проекты яисә линияле объектлар төзү чорында бирелгән авыл хуҗалыгында файдалана торган җирләр өлешен рекультивацияләү проекты;<br>10) гомуми кулланудагы автомобиль юллары буендагы полосалары һәм отвод | |

| | | |
|---|---|---|
| | полосалары чигендәге җир кишәрлеген күчергән очракта – килештерүләр:<br>дәүләт хакимиятенең башкарма органы, җирле хакимият (муниципаль берәмлекнең башкарма-эш йөртү органы), Россия Федерациясе законнарына туры китереп, автомобиль юлларына иялек хокукы булган физик яки юридик затлар;<br>«Юл хәрәкәте иминлеге» республика дәүләт учреждениесе (җир кишәрлекләре Татарстан Республикасы региональ дәрәҗәдәге гомуми кулланудагы автомобиль юллары буендагы полосаларында урнашкан очракларда)<br>Физик затлар гариза бирүченең шәхесен раслаган документларның күчермәсен дә тапшыралар.<br>Документларның күчермәсе (8 подпунктта күрсәтелгәннәрдән тыш) нотариуста яисә документның оригиналын биргән органда (оешма, учреждение) расланган булмаса, оригиналлары да тәкъдим ителә һәм Министрлык белгече тарафыннан раслана. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга | Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек | |

| | | |
|---|---|---|
| туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | кысасында алыналар:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Министрлыкка үтенечнамә бирелгән көннән бер айдан да артык булмаган вакытка өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән).<br>2. Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан Министрлыкка үтенечнамә бирелгән көннән бер айдан да артык булмаган вакытка өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән).<br>3. Җир кишәрлеге дәүләт кадастрыннан өземтә - җир кишәрлегенең кадастр паспорты яисә соралган җыр кишәрлеге турында Министрлыкка үтенечнамә бирелгән көннән бер айдан да артык булмаган вакытка кадастр өземтәсе («Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалыннан)<br>4. Күчемсез милеккә һәм алар белән бәйле алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрында Министрлыкка үтенечнамә | |

| | | |
|---|---|---|
| | бирелгән көннән алты айдан да артык булмаган вакытка кадастр өземтәсе (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль идарәсе)<br>5. Соралган җир кишәрлегендә урнаштырылырга ниятләнгән объектның территорияне планлаштыруның расланган документларына туры килүе турында муниципаль берәмлекнең башкарма-эш йөртү органының бәяләмәсе һәм территорияне планлаштыруның расланган документларының шартлы билгеләмәләр, соралган җир кишәрлегенең чикләре күрсәтелгән, вәкаләтле вазыйфаи зат имзалаган, тиешле дәрәҗәдәге копировкаланган күчермәсе (соралган җир кишәрлегендә, төзелеш, реконструкция һәм скважиналарны эксплуатацияләү һәм башка нефть чыгаручы оешмалар объектларыннан тыш, лицензияләнгән территория чикләрендә бөтен Татарстан Республикасы территориясендә, лицензиясе буенча җир асты байлыкларыннан файдалану өчен зарур булган федераль дәрәҗәдәге, җирле | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәрәҗәдәге, республика дәрәҗәсендәге, объект урнаштырылырга ниятләнгән, шулай ук, табигый битумлы урыннар булган очраклар).<br>Өстә күрсәтелгән документларгы гариза бирүчеләр мөсәкыйль тапшыра алалар.<br>Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документлар кабул итүдән баш тарту өчен нигез була алмый. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен түбәндәге килештерүләр таләп ителә:<br>Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;<br>Идел буе федераль округы буенча җир асты байлыкларыннан файдалану Департаментының Татарстан Республикасы буенча геология һәм лицензия бүлеге (файдалы казылмалар чыгару белән бәйле очраклардан тыш);<br>Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы;<br>Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (файдалы | ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | казылмалар чыгару белән бәйле очраклардан тыш). | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре каралмаган | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законда каралмаган.<br>Үтенечнамәне караудан баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Үтенечнамә белән тиеш булмаган затның мөрәҗәгать итүе.<br>2. Үтенечнамәгә составы, формасы яисә эчтәлеге җир законнары таләпләренә туры килми торган документлар теркәлгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен (күчерүдән баш тарту) нигезләр:<br>1. Федераль законнарга туры китереп җирне яисә шушы җир составындагы җир кишәрлекләрен бер категориядән башкасына күчерү тыелган булу.<br>2. Дәүләт экологик экспертизасының кире бәяләмәсе булу (аны үткәрү федераль законнарда каралса). | РФ ҖК;<br>ст.ст.3,4 Федераль закона № 172-ФЗ;<br>ТР МК карары № 523 |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. Җир һәм җир кишәрлекләренең максатчан билгеләмәсе территориаль планлаштыруның расланган документларына һәм территорияне планлаштыру документациясенә, җир ясау документациясенә туры килмәве билгеле булу. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри дәүләт хезмәтләре түләүсез күрсәтелә. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 | РФ Президенты Указы № 601, п. 1 |

| | | |
|---|---|---|
| максималь срогы | минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы | Үтенечнамә кергән көндә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка таләпләр | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү тиешле күрсәткечләр белән җиһазланган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелүчеләр әлеге максатлар өчен бүлеп бирелгән,<br>һаваны суыту-җылыту системасы;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар тутыру өчен җиһаз;<br>Татарстан Республикасы Интеграцияләнгән дәүләт телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск;<br>мәгълүмати стенд белән җиһазландырылган,<br>инвалидлар каршылыксыз керә ала торган чаралар һәм җайланмалар белән җиһазландырылган урыннарда башкарыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм аның вакыт буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең ераклаштырылган эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып | күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидлар дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыксыз керә ала торган чаралар һәм җайланмалар белән тәэмин итү;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>мәгълүмати стендларда һәм “Интернет” челтәрендә, рәсми сайтта (http://mzio.tatarstan.ru) дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>әлеге регламентның Министрлык белгечләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) | |

| | | |
|---|---|---|
| | булуы;<br>гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>гариза бирүче шәхсән үзе мөрәҗәгать иткән очракта министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеше бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артык түгел.<br>Мөрәҗәгатьне һәм документларын почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.<br>Гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче белгеч белән үзара бәйләнеше вакыты 15 минуттан да артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турындагы мәгълүматны гариза бирүче рәсми сайттан (http://mzio.tatarstan.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) алырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган | |

| | | |
|---|---|---|
| | эш урыннарында күрсәтелми. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтелми | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре, шулай ук, административ процедураларның күп функцияле үзәкләрдә, күп функцияле үзәкләрнең дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча ераклаштырылган эш урыннарында

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

үтенечнамәне һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомоствоара запрослар формалаштыру һәм юллау, норматив хокукый актларда каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтүне дәүләт хакимияте органнары белән килештерү;

үтенечнамәгә беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карау; гариза бирүчегә үтенечнамәне караудан баш тарту турында хат юллау;

авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проекты әзерләү;

авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын гариза бирүчегә юллау.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 2 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат

белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (гариза теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, шулай ук, күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Үтенечнамәне һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән үтенечнамәсен эш башкару бүлегенә бирә (юллый) яисә күрсәтелгән документларны почта аша юллый.

3.3.2. Эш башкару бүлеге белгече Бүлек белгече катнашында үтенечнамәне һәм документларны кабул итә, терки һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлеккә юлланган үтенечнамә һәм беркетелгән документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау; норматив хокукый актларда каралган очракларда дәүләт хезмәте күрсәтүне дәүләт хакимияте органнары белән килештерү.

3.4.1. Бүлек белгече үтенечнамәне һәм документларны эш башкару бүлегеннән алганнан соң “ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеге бирү турында үтенечнамәләр үтү бите”н (1 нче кушымта) тутыра һәм ведомоствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада запрослар юллый:

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә (алга таба – ФСХ ТРИ) – Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЮЗБДР) яисә Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ШЭБДР) гариза бирүче юридик зат турында мәгълүмат бирүне сорап;

Дәүләт күчемсез милек кадастрыннан (ДКМК) белешмә – җир кишәрлеге турында кадастр өземтәсе яки җир кишәрлегенә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсе филиалына (алга таба – Росреестр ТРИ) үтенечнамә биргәннән соң бер елдан да артмаган срокка кадастр паспорты бирү турында;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә (алга таба – Росреестр ТРИ) – алынасы җир кишәрлегенә хокук турында Күчемсез милек һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокуклар Бердәм дәүләт реестрыннан (ХБДР) белешмә бирү турында;

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: мәгълүматлар (документлар) бирү турында юлланган запрослар

3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре 3.4.1 пунктта ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән алда күрсәтелгән запрослар нигезендә тиешле срокларда соралган документларны (мәгълүматны) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган мәгълүмат (документлар), яисә, баш тарту турында министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.4.3. Әлеге Регламентның 3.3.2 пунктына туры китереп, ФСХ ТРИдән, Росреестр ТРИдән, “ТР ФКП” ФБУдан соратып алынган мәгълүматлар килгәннән соң, Бүлек белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада запрослар юллый:

муниципаль берәмлекнең башкарма-эш йөртү органына соралган җир кишәрлегендә урнаштырылырга ниятләнгән объектның территорияне планлаштыруның расланган документларына туры килүе (туры килмәве) турында бәяләмәсен һәм территорияне планлаштыруның расланган документларының шартлы билгеләмәләр, соралган җир кишәрлегенең чикләре күрсәтелгән, вәкаләтле вазыйфаи зат имзалаган, тиешле дәрәҗәдәге копировкаланган күчермәсен (соралган җир кишәрлегендә, төзелеш, реконструкция һәм скважиналарны эксплуатацияләү һәм башка нефть чыгаручы оешмалар объектларыннан тыш, лицензияләнгән территория чикләрендә бөтен Татарстан Республикасы территориясендә, лицензиясе буенча җир асты байлыкларыннан файдалану өчен зарур булган федераль дәрәҗәдәге, җирле дәрәҗәдәге, республика дәрәҗәсендәге, объект урнаштырылырга ниятләнгән, шулай ук, табигый битумлы урыннар булган очраклар) сорап;

җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүне килештерү турында:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына (алга таба – ТР ММ);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына (алга – ТР Минэкология);

Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларын файдалану департаментының Татарстан Республикасы буенча лицензияләү һәм геология бүлегенә (файдалы казылмалар чыгару белән бәйле очраклардан тыш);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – ТР АХМ) (файдалы казылмалар чыгару белән бәйле очраклардан тыш);

Әлеге пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: юлланган запрослар: туры килү (туры килмәү) турында бәяләмә, җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүне килештерү турында.

3.4.4. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре 3.4.3 пунктта ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән алда күрсәтелгән запрослар нигезендә туры килү (туры килмәү) турында, җир кишәрлеген бер категориядән башкасына күчерүне килештерү турында бәяләмәне тиешле срокларда бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запроска җавап буларак Министрлыкка юлланган бәяләмә (килештерү).

3.5. Үтенечнамәгә беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карап чыгу; гариза бирүчегә үтенечнамәне караудан баш тарту турында хат юллау.

3.5.1. Әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларына туры китереп юлланган запрослар белән соратып алынган мәгълүмат килгәннән соң, Бүлек белгече үтенечнамәгә беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карап, үтенечнамәне караудан баш тарта торган Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә;

3.5.2. Үтенечнамәне караудан баш тарта торган Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра: үтенечнамәне караудан баш тарту турында хат әзерли һәм аны Бүлек мөдире, Җир ресурслары идарәсе башлыгы, хокук идарәсе башлыгы белән килештерүне, үтенечнамәне караудан баш тарту турында хатны министрның беренче урынбасары имзалавын һәм аны гариза бирүчегә Министрлыкның эш башкару буенча Инструкциясендә билгеләнгән тәртиптә юллауны тәэмин итә.

3.5.1, 3.5.2 пунктлар белән билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларына туры китереп юлланган запросларга җавап алынганнан соң өч көн эчендә тормышка ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: гариза бирүчегә үтенечне караудан баш тарту турында хат юллау

3.6. Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын әзерләү (алга таба – ТР МК карары проекты), ТР МК карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллау

3.6.1. Үтенечнамәне караудан баш тарту өчен нигез булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

карау: үтенечнамә һәм аңа беркетелгән документлар; Министрлык юллаган запросларга җаваплар (мәгълүмат, документлар);

авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарта торган Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерү;

үтенечнамәне һәм аңа беркетелгән документларны карап, нәтиҗәсе буенча ТР МК карары проектын әзерләү һәм ТР МК карары проектын, бергә теркәп җибәрелә торган хат белән, килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты белән ТР МК карары проекты.

3.6.2. Бүлек мөдире ТР МК карары проектын, бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын карый һәм проектларны Җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына килештерү өчен юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелеп, Идарә башлыгына килештерергә юлланган ТР МК карары проекты, бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты.

3.6.3. Идарә башлыгы әзерләнгән ТР МК карары проектын, бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын карый, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгына килештергән проектлар.

3.6.4. Бүлек белгече ТР МК карары проектын, бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын Министрлыкның хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсенә җибәрелгән ТР МК карары проекты, бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты.

3.6.5. Хокук идарәсе белгече: ТР МК карары проектына хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза уздыра, бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын карый, килештерә һәм килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый яисә ТР МК карары проектына хокук идарәсе бәяләмәсен (кисәтүләр булган очракта) имзаларга юллый.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: ТР МК карары проектына хокук идарәсенең бәяләмәсе яисә килештерелеп, хокук идарәсе башлыгына юлланган ТР МК карары проекты һәм бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты.

3.6.6. Хокук идарәсе башлыгы хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза буенча ТР МК карары проектын, бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын килештерә, яисә ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсе бәяләмәсен имзалый һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә юлланган хокук идарәсе башлыгы килештергән ТР МК карары проекты, бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты яисә ТР МК карары проекты буенча хокук идарәсенең имзаланган бәяләмәсе.

3.6.7. Бүлек белгече ТР МК карары проекты буенча бәяләмә алган очракта кимчелекләрне төзәтә һәм ТР МК карары проектын, бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты белән, хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.6.8. Хокук идарәсе башлыгы хокук идарәсе бәяләмәсендәге кимчелекләрнең төзәтелү фактын тикшерә һәм ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын килештерә

3.6.7 и 3.6.8 пунктларда билгеләнгән процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты

3.6.9. Бүлек белгече ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын министрның беренче урынбасарына килештерергә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасарына килештерергә юлланган ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты.

3.6.10. Министрның беренче урынбасарына ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын килештерә һәм имзалау өчен министрга юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: имзалау өчен министрга юлланган ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты.

3.6.11. Министр ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектына имза куя һәм теркәү өчен эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Теркәү өчен эш башкару бүлегенә юлланган имзаланган ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты, килештерелгән ТР МК карары проекты.

3.6.12. Эш башкару бүлеге белгече бергә теркәп җибәрелә торган хат белән бергә ТР МК карары проектын терки һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган бергә теркәп җибәрелә торган хат белән бергә ТР МК карары проекты.

3.7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентында билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ТР МК карары проектын карый.

Процедуралар нәтиҗәсе: Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында яисә авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерүдән баш тарту турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар)

3.8. Гариза бирүчегә күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) юллау.

Бүлек белгече Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан күчерү турында карарның (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсе кергәннән соң бергә теркәп җибәрә торган хат әзерли, министрның беренче урынбасарының имзасын, эш башкару бүлегендә теркәлүне һәм, Министрлыкның эш башкару буенча Инструкциясендә билгеләнгән тәртиптә, бергә теркәп җибәрә торган хат белән күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсен гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә.

Әлеге пункт билгели торган процедура Министрлыкка күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) кергәннән соң өч көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Гариза бирүчегә юлланган күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсе белән аңа бергә теркәп җибәрә торган хат

3.9. Дәүләт хезмәте электрон формада, күпфункцияле үзәкләр, күпфункцияле үзәкләрнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыны аша күрсәтелми.

3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән техник хаталарны төзәтү:

3.10.1. Гариза бирүченең күчерү турында Министрлык карарында техник хата китү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаны төзәтелүенә нигез булып тора.

Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче түбәндәгеләрне бирә:

техник хаталарны төзәтү турында мөрәҗәгать (3 нче кушымта);

күчерү турында карар;

техник хатаның булуы дәлилләнгән документлар.

3.10.2. Күчерү буенча карарда техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьне гариза бирүче Министрлыкка тапшыра яисә почта аша юллый.

3.10.3. Эш башкару бүлеге белгече кабул итеп ала һәм мөрәҗәгатьне, беркетелгән документлары белән бергә, теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура мөрәҗәгать һәм документлар бирелгән (кергән) көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Карау өчен Бүлек белгеченә юлланган мөрәҗәгать.

3.10.4. Бүлек белгече документларны карап чыга һәм Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында Министрлык карарына үзгәрешләр кертү турында Министрлык карары

проектын (үзгәрешләр кертү турында карар проекты) әзерли. Үзгәрешләр кертү турында карар проекты әзерләнгәч әлеге Регламентның 3.6.2. 3.6.3, 3.6.9-3.6.12 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан хата җибәрелү турында мөрәҗәгать алган көннән соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган үзгәрешләр кертү турында карар проекты һәм аның гариза бирүчегә юллануы.

3.10.5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган үзгәрешләр кертү турында карар килгәннән соң Бүлек белгече бергә теркәп җибәрелә торган хат әзерли, аны министрның беренче урынбасары имзалавын, эш башкару бүлегендә теркәлевен һәм үзгәрешләр кертү турында карар һәм бергә теркәп җибәрелә торган хат белән гариза бирүчегә юлланывын тәэмин итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура күчерү турында карар Министрлыкка килгән көннән соң өч көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган үзгәрешләр кертү турында карар белән бергә теркәп җибәрелә торган хат.

3.10.6. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документларны (теркәлгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, үзгәрешләр кертү турында карар) Бүлек белгече Министрлыкта булган үзгәрешләр кертү турында карар нөсхәсенә беркетә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчесе әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган

мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз өченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча).

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Идарә эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерүгә хокуклы.

Министрның карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

Министр урынбасарының, дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять министр исеменә бирелә.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

5.3. Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең ераклаштырылган эш урыны аша, рәсми

сайт (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш::

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре. Гариза бирүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Министрлыкка кергән шикаять шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләте булган вазыйфаи зат тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, Министрлык, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында карап тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән Административ регламентына 1 нче кушымта

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында җир кишәрлеген Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү турында үтенечнамәнең үтү кәгазе

Гариза керү датасы «_____»_____________
Гариза бирүче ____________________________________________________
Теркәү (кергән) номеры ____________________________

| /п | Министрлыкның структур бүлекчәсе | Алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Эш башкару һәм контроль бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең Җирләрнең категориясен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктларның чикләренә кертү бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе мөдире | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 8. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 9. | Эш башкару һәм контроль бүлеге (документларны рәсмиләштерү һәм теркәү) | | | | |

Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән Административ регламентына 2 нче кушымта

## Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасы

Гариза бирүче

Гариза бирүче әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән бергә үтенечнамә тапшыра яисә почта аша юллый

Үтенечнамә һәм аңа беркетелгән документлар

Эш башкару бүлеге белгече

Документлар кабул итү, үтенечнамәне һәм документларны теркәү (Бүлек белгече белән бергә) 1 көн

Кабул ителгән, теркәлгән документлар

Бүлек белгече

Запрослар әзерли һәм җаваплар ала: запрослар буенча мәгълүмат (документлар) 2 көн

Запрослар: ФСХ ТРИга, ЮЗБДРга яисә ШЭБДРга 5 көн

Запрослар: күчерүне килештерүләр турында – ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына, ТР Мәдәният министрлыгына, ТР Экология министрлыгына, Идел буе федераль округы буенча Җир асты байлыкларын файдалану департаментының ТР буенча лицензияләү һәм геология бүлегенә – күздә тотылган объектны урнаштыруның территориаль планлаштыруга туры килүе турында бәяләмә сорап 5 көн

Бүлек белгече

Үтенечнамәгә беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карый, үтенечнамәне караудан баш тарта торган Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерү, алар булганда гариза бирүчегә үтенечнамәне караудан баш тарту турында хат юллый. 3 көн


Үтенечнамәне караудан баш тарту турында гариза бирүчегә хат

Үтенечнамәне караудан баш тарту өчен нигезләр булмаган документлар

Бүлек белгече

Үтенечнамәгә беркетелгән документларның составын, формасын һәм эчтәлеген карый, үтенечнамәне караудан баш тарта торган Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерү, МК карары проектын, бергә кушып җибәрелә торган әзерли 3 көн

ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты


Начальник Отдела
ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын карый һәм килештерә
Килештерелгән ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты
Идарә башлыгы
ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын карый һәм килештерә 2 көн
Килештерелгән ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты
Бүлек белгече
Бүлек мөдире һәм идарә башыгы белән килештерелгән ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын хокук идарәсенә юллый
Хокук идарәсенә юлланган килештерелгән ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты
Хокук идарәсе белгече
ТР МК карары проектына хокукый экспертиза ясый, ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын карый 2 көн
ТР МК карары проекты буенча бәяләмә яисә килештерелгән ТР МК карары проекты
Хокук идарәсе башлыгы
ТР МК карары проектына бәяләмәне имзалый яисә ТР МК карары проектын һәм бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын килештерә 1 көн
Килештерелгән ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат
ТР МК карары проекты буенча бәяләмә
Бүлек белгече
ТР МК карары проекты буенча бәяләмә алган очракта күрсәтелгән кимчелекләрне төзәтә һәм ТР МК карары проектын, бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты белән, кабат хокук идарәсе башлыгына юллый
Хокукый экспертизага юлланган ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты
Хокук идарәсе башлыгы
ТР МК карары проекты буенча бәяләмәне имзалый яисә ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын килештерә 2 көн
Килештерелгән ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты
Бүлек белгече
ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын министрның беренче урынбасарына юллый
Министрның беренче урынбасарына юлланган ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты

Министрның беренче урынбасары

ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын килештерә һәм имзалау өчен министрга юллый
1 көн

Килештерелгән ТР МК карары проекты белән бергә теркәп җибәрелә торган хат проектын

Министр

Бергә теркәп җибәрелә торган ны имзалый, ТР МК карары проектын килештерә
1 көн

Имзаланган бергә теркәп җибәрелә торган хат проекты һәм килештерлгән ТР МК карары проекты

Эш башкару бүлеге белгече

Бергә теркәп җибәрелә торган хат белән бергә ТР МК карары проектын терки һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юллый; үтенечнамәне караудан баш тарту турында хатны терки һәм гариза бирүчегә юллый
1 көн

Үтенечнамәне караудан баш тарту турында гариза бирүчегә юлланган хат

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланган Бергә теркәп җибәрелә торган хат белән бергә ТР МК карары проекты

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

ТР МК карары проекты
30 көн

Күчерү турында (күчерүдән баш тарту турында) карар

Бүлек белгече

Күчерү турында карарның (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсенә бергә теркәп җибәрә торган хат әзерли, министрның беренче урынбасарының имзасын, эш башкару бүлегендә теркәлүне һәм бергә теркәп җибәрә торган хат белән күчерү турында карар (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсен гариза бирүчегә юллануын тәэмин итә.

Күчерү турында карарның (күчерүдән баш тарту турында карар) күчермәсе белән бергә гариза бирүчегә юлланган хат

Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән Административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

Техник хатаны төзәтү турында гариза

______________________________________________________________________________
(юридик затның атамасы, физик затның, шәхси эшмәкәрнең Ф.И.ӘИ.)
____________________________________________________________________________,
(вәкилнең Ф.И.ӘИ, вазыйфасы)
_________________________________________________________ нигезендә эш итүче
(вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ)
Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «____»_________ 20______ел. №________ карарына тиешле үзгәртүләрне кертүне үтенә

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «____»_________«____»_________ 20______г. №________карарында
_________________________________________________________________ дип язылган
Дөрес белешмә:__________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Гариза бирүче (гариза бирүчеләр) турында белешмә:

| | |
|---|---|
| Юридик зат реквизитлары (ОГРН, ИНН, адрес (урнашкан урыны) Физик зат өчен (юридик затның вәкиле) паспорт мәгълүматлары (серия, номер, кем кайчан биргән, подразделение коды, теркәлү адресы), Яшәгән адресы (теркәлү адресы белән туры килмәгән очракта), ИНН | |
| Телефон, почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы | |
| Җир кишәрлеге турында мәгълүмат | |

| | |
|---|---|
| Кадастр номеры | |
| Җир кишерлегенең урнашкан урыны | |

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (____________________ номерлы ышанычнамә буенча вәкил
_________________________________________/________________________/
(вәкилнең фамилиясе, исеме, этисенең исеме, имза)

М.П. (мөһер булса)

Мөрәҗәгать кабул ителде: "___"__________ 20__ г.
______/__________________/имза, мөрәҗәгатьне кабул иткән белгечнең фамилиясе, инициаллары

Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең теркәлгән Административ регламентына кушымта (белешмә)

## Авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җирләрдән җир кишәрлеген башка категориягә күчерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Демидов Сергей Анатольевич | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсе башлыгы<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире Галиев Артур Ирек улы | 221-40-89 | Artur.Galiev@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83<br>221-40-79 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе Мостафин Айрат Рафинант улы | 264-77-15 | Ayrat.Mustafin@tatar.ru |
| Идарә башлыгы урынбасары<br>Аксанов Валерий Аркадьевич | 264-76-89 | Valeriy.Aksanov@tatar.ru |